Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

21 февраль 2019 ел № 07

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә Әлмәт муниципаль районында һәм Әлмәт шәһәрендә халык алдында тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмәгә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә - 3.7 нче код җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча – “дини файдалану”, 16:45:010106:6 кадастр номеры, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай проспекты, 14 йорт адресы буенча урнашкан, шәхси торак төзелешенең территориаль зонасына (Ж-1) кертелгән җир кишәрлегенә карата «конфессиональ объектлар» рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 1 мартында 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң кимендә ике һәм дүрт айдан да артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4 Җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе" муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 1 мартына кадәр.

3. "Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы А.Р. Хайруллин